ФОМА УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ МӘКТӘБЕ УКУЧЫЛАРЫНЫҢ АЙЛЫК ГАЗЕТАСЫ

# «КӨЗГЕ»

**СЕНТЯБРЬ, 2017 нче ел**
**№ 1 (32)**

## ҮЗЕҢ НИНДИ, КӨЗГЕҢ ШУНДЫЙ!!!






Беренче сентябрь иртәсе кояшлы да, болытлы да, яңгырлы да була. Шулай да андый иртәләрнең һәрберсе күңелгә кояшлы булып иңә. Ничек шулай булмасын! Белем иле юлыннан беренче адымын ясый бит бала, киләчәгенә юл яра! Ул матур итеп киенгән, бер кулында — портфель, икенчесендә — чәчәкләр. Әлеге көн һәр кешенең дә диярлек күңелендә сакланадыр. Мәктәптә уку еллары безнең тормышыбызда зур урын алып тора. Мәктәпне тәмамлаган чакта без инде тагын да зуррак юлга адым атлар кешеләр булып тәрбияләнеп чыгабыз. Мәктәптә безне дөньяның төрле төбәкләренә китәргә сәләтле итеп талантлы укытучылар укыта. 2016-2017нче ел нәтиҗәләре буенча мәктәп Татарстанның иң яхшы 100 авыл мәктәбе исемлегендә. Быел мәктәбебездә зур уңышка ирешкән укытучыларыбыз байтак булды. Менә алар: Сафиуллин Халим Салих улы,Хайруллина Лилия Йосыф кызы, Сөләйманова Раилә Заһит кызы, Ситдикова Клара Касыймовна, Садретдинова Гөлназ Ринат кызы, Фахреева Гөлфия Якуп кызы,Абрахманов Рәис Азат улы, Тарасова Снежанна Анатольевна һ.б.

Әйе, бала мәктәптә белемгә омтыла, якты киләчәгенә кул сузып бара! Алдында — биек үрләр, шул үрләрне яулый алса гына, ул бәхетле булачак. Аңа шушы үрләрне яулауда, белем алуда укытучы ярдәмгә килә.

Укытучы! Изге бер сүз ул. Һәр кеше бу сүзнең мәгънәсенә төшенә.Укытучы бөтен көчен биреп, бөтен яхшылыкны укучыларының күңеленә сеңдерергә тырыша: җирне, тормышны аңларга, аны яратырга өйрәтә.

Укучыларны, аларның әти-әниләрен һәм укытучыларын чын күңелдән бүгенге Белем бәйрәме белән тәбрик итәбез! Укуыгызда уңышлар, ныклы сәламәтлек,белемнәр алган вакытта күзләрегездә очкыннар ялтырап торуын телибез! Иң ныклы белем үз туган телеңдә алынган белемнәр!

**Бу санда:**

| | |
|---|---|
| Белем бәйрәме | 1 |
| «Тынычлык» сыйныф сәгатьләре | 2 |
| Авыл укытучысы - 2017 | 3 |
| Актуаль мәсьәлә | 4 |
| Гаилә һөнәре дәвамлы | 5 |
| Варислар туган көне | 5 |
| Алтын каләм—2017 | 6 |

# «Тынычлык» мәктәптә беренче сыйныф сәгатьләре

Яңа 2017-2018нче уку елы башлануын хәбәр итеп яңгыраган кыңгырау укучыларны классларга дәште. Чыгарылыш сыйныф укучылары быел беренче тапкыр мәктәп бусагасын атлап кергән 6 сабыйны беренче укытучылары Ахметова Рузилә Әсхәт кызы канаты астында үз классларына озатты. Алар:

1.Валиуллин Нияз Наил улы
2.Зиатдинов Эмиль Фәнис улы
3.Камалова Диләрә Илнур кызы
4.Киямов Зөлфәт Зөфәр улы
5.Хайбуллина Фатима Марат кызы
6.Шавалеев Әлфис Фәрит улы.

Яңа уку елының беренче тәрбия сәгате тынычлык темасына багышланды. Агымдагы елда мәктәптә 89 бала парта артына утырды. Беренче класста 6 бала укыса, тугызынчыда – ун, ә унберләр бишәү.

***Хайруллина Әдилә,***

*6 нчы сыйныф.*

## Фоторепортаж












## Конкурслар



# «Авыл укытучысы – 2017» конкурсы «Тема тирәнлеге» номинациясендә укытучыбыз Аглиуллина Гөлүсә Дамир кызы җиңүче.

“Мәгариф” журналы оештырган “Авыл укытучысы-2017” конкурсының беренче туры тәмамланды
Бу бәйгедә безнең мәктәпнең югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы Аглиуллина Гөлүсә Дамир кызы да үз көчен сынап карарга теләк белдерде.

Әлеге конкурсны “Мәгариф” журналы 2014 елда оештырып җибәргән иде. Быел ул дүртенче тапкыр уздырыла, һәм аны үткәрүдә Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы да үз өлешен кертә. Конкурска республика авыл мәктәпләреннән 100гә якын эш килгән. Шуларның 30ы икенче турга сайлап алынды.

**Казанның Ш.Мәрҗани исемендәге 2 нче татар гимназиясендә «Авыл укытучысы-2017» конкурсының финал өлеше тәмамланды.**
3 этапка узучылар һәркайсы эчтәлекле, кызык, заманча дәресләр күрсәтте. Җиңүчеләр арасында баллар аермасы бик аз булу да конкурсантларның бик көчле булуларын исбатлый.

Мәртәбәле жюри составына ТР мәгариф һәм фән министрлыгы, ТР мәгарифне үстерү институты, «Мәгариф» журналы хезмәткәрләре, »Авыл укытучысы» һәм «Ел укытучысы» конкурсларында җиңүче мөгаллимнәр кергән459 балл җыеп, Биектау районы Суыксу урта мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Клара Гарипова «Авыл укытучысы-2017» конкурсының җиңүчесе булды. Икенче урында 446 балл белән Әгерҗе районы Тирсә гомуми урта белем бирү мәктәбенең беренче квалификацион категорияле математика укытучысы Гөлназ Вәлиева, өченче урында 444 балл белән Балтач районы Карадуган бакчасы тәрбиячесе Раушания Нигъмәтуллина.

Төрле номинацияләрдә җиңүчеләр:

**“Балаларга мәхәббәт”** номинациясендә – Мөслим лицееның татар теле һәм әдәбияты укытучысы Чулпан Сыйтдикова.

**“Тема тирәнлеге ”** номинациясендә – Нурлат районы Фома урта мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Гөлүсә Әһлиуллина.

**“Белемнең көнкүрештә чагылышы”** номинациясендә – Мөслим районы Мөслим гимназиясенең башлангыч сыйныфлар укытучысы Ләйсән Мортазина.


**“Активлык тарафдары”** номинациясендә – Актаныштагы сәламәтлеге чикләнгән балалар өчен гуманитар гимназия-интернатның татар теле һәм әдәбияты укытучысы Чулпан Шәрипова.


**“Предметка мәхәббәт”** номинациясендә – Тукай районы Мусабай-Завода мәктәбеукытучысы Флюра Абдуллина.

(*Информация «Мщгариф» журналыннан алынды*)

## Укучылар иҗаты







Аглиуллина Алинә,
11 нче сыйныф

***Актуаль мәсьәлә***

# Грippка каршы вакцинация башланды

Йогышлы чирләр структурасында 95 процентны биләп торучы грипп һәм кискен респиратор йогышлы авырулар халык сәламәтлегенә җитди зыян сала. Табиблар сүзләренә караганда, грипп үзе түгел, ә ул китергән өзлегүләр куркыныч. 1997-1998 елларда Татарстанда грипп белән авыручылар саны 300- 400 меңгә җиткән, соңгы елларда ул 3- 4 мең кеше тәшкил итә. Грippка каршы түләүсез вакцинация укытучыларга, мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре, медицина хезмәткәрләренә, 60 яшьтән өлкән кешеләргә ясала. Аллергия реакциясе булган һәм тавык аксымын кабул итә алмаган кешеләргә вакцинация ясау киңәш ителми.

–Әгәр сездә авыру билгеләре: тән температурасының күтәрелүе, тирләү, хәлсезлек, буыннар, мускуллар, баш авырту, көчле (авырту белән) ютәл, томау, гиперемия, авыз эче һәм тамакның кипшенүе күзәтелсә, белеп торыгыз – Сез грипп эләктергәнсез. Үз белдегең белән дәваланмаска, кичекмәстән табибка күренергә кирәк,-дип кисәтә бу уңайдан Гүзәлия Маликова.

Вакцина ясату (профилактика) бу авырудан саклануның кулай чарасы булып тора. Хезмәт коллективларында хезмәткәрләрнең 70-80%на вакцина ясау бу коллективта авыру ихтималын нык чикли.

–Грippка каршы вакцинаны, гадәттә, ел саен октябрь-ноябрь айларында ясыйлар. Вакцина ясалгач, 2 атнадан соң иммунитет көчәя һәм грипп вирусына каршы антитәнчекләр эшләп чыгарыла,-ди баш табиб урынбасары.– Грипптан саклану өчен кулларны һәрвакыт сабынлап юарга, сәламәт яшәү ревеше алып барырга: туйганчы йокларга, файдалы ризыклар ашарга, актив булырга, күбрәк сыеклык эчәргә, кеше күп җыела торган җирләрдә булмаска тырышырга, саф һавада күбрәк йөрергә, сулыш органнарын саклау өчен маскалар кияргә.

Хисматова Зәринә, 6 нчы сыйныф.



## *Эш эшләсәң эш көне– тук булырсың кыш көне*

Быел мәктәп яны участогында җиләк—җимеш һәм яшелчәләр үстердек. Менә ниһаять барлык яшелчәләрне җыеп алыр чак җитте. Быел көннәрнең җылы шул ук вакытта яңгырлы булуы мул уңыш җыеп алырга ярдәм итте. Балалар да шатланып бакчада эшләделәр, чөнки өстәлләр дә ел әйләнәсендә витаминлы салатлар бер дә бетми. Хезмәт кешене чыныктыра, ә балалар шуны аңлапмы бик теләп хезмәт куйдылар.

Аглетдинова Гөлләр, 6 нчы сыйныф.



# Гаилә һөнәре дәвамлы



Быел мәктәпнең 9нчы сыйныфына укырга килүче Абдрахманова Рәзилә Роберт кызы тирә-якны үзенең комбайнчы кыз булуы белән таң калдырды.

Урак чорында әтисе Роберт Азат улы белән бер рәттән «Сөләйманов Ә.И.» крестьян – фермерлык хуҗалыгында Рәзилә дә тырыш хезмәт куеп эшләде. Эшкә быел беренче генә чыкса да, техника белән кызыксынуы күптәннән икән инде Рузиләнең, моңа кадәр дә әтисенә ияреп басуга килгәли торган булган.Әтисе Роберт Абрахманов - хуҗалыкның алдынгы комбайнчысы, урак чорында көнне-төнгә ялгап эшләргә, күп көч һәм тырышлык куярга кирәк булачагын да үз күзләре белән күреп белгән. Шулай да быел батырчылык иткән—басуга алып чык әле дип әтисенә үзе тәкъдим иткән.

- Шатланып риза булдым, - ди Роберт. Кайчандыр үзем дә комбайнчы әтиемә 5 нче сыйныфтан ук ярдәмче булып кырга чыккан идем. Техника, игенче һөнәре серләренә аңардан өйрәндем. 8 нче сыйныфта инде үзмә комбайнны ышанып тапшырдылар. Рәзиләнең теләге бар икән, нигә каршы килергә, ди. Шөкер сынатмады, урак буена янәшә торып эшләдек.

Әтисе белән бергә ремонтка да йөргән, урак башлангач, руль артына да утырган Рәзилә. Иртәнге 5 тән төнге 11-12 гә кадәр эшләргә туры килгәндә дә сер бирмәгән. Бүген инде ул парта арасында классташлары белән бергә мәктәптә белем ала. Ә җәйге каникулларда кырда үткәргән көннәрен сагынып искә төшерә.

- Янәшәдә әти булгач, бер дә авыр булмады. Барысына да өйрәтеп, киңәш биреп торды, ярдәм итте. Киләсе елга да уракка чыгам, - ди ул.

Әтисе дә киләсе сезонда кызы белән эшләүгә каршы түгел. Дөрес, комбайнчы хезмәте ир-егетләр өчен дә җиңелләрдән түгел. Әмма хезмәт белән чыныгып үскәннәргә тормышта җиңелрәк булачак, дип санный Роберт Азат улы. Тырышлыклары бушка булмады,  Рәзилә белән бергәләшеп эшләп, хуҗалыкта икенче урынга чыктылар. Быелгы уңышы аеруча кадерле аңа, чөнки бусында кызының да өлеше кергән бит.

****

# Сәламәтлек көне



13 нче сентябрь көнне Нурлатта укытучыларның җәйге спартакиадасы булып узды.Безнең мәктәп данын якларга укытучылар барды. Сулейманова Раилә белән Гирфанова Ралия аркан тартуда катнаштылар. Раилә Загитовна 1 нче урын яулады. Галлямова Гөлүсә белән Садртдинова Рузилә 100 м га йөгерүдә, ә Замалиев Айрат ату буенча көчләрен сынадылар. Шул ук көн мәктәптә дә «Сәламәтлек көне» дип игълан ителде. Форсаттан файдаланып 1 –11 нче сыйныф укучылары җиңел атлетика буенча ГТО нормаларын тапшырдылар. Укытучылар да читтә калмады. Алар иң беренчеләрдән булып 1 км га йөгерделәр. Аларга укыткан укучылары көч– куәт биреп йөрәкләрен җилкендереп тордылар. Бар кеше дә бу көннән канәгать калды. Ә нәтиҗәләр түбәндәгедән гыйбарәт:



| Сыйныф | I | II | III |
|---|---|---|---|
| 5 | Билданов Р. | Тагиров Г. | Щербаков Т |
| 6 | Гайнуллина А. | Тагиров Б. | Тагиров И |
| 7 | Хисматов Р. | Ибрагимов З. | Галиуллин И. |
| 8 | Садртдинов А. | Мингалимов Н. | Гумеров Р. |
| 9 | Шагиахметов И. | Галиуллин Р. | Аглиуллин А. |
| 10 | Мингалимов И. | Замалиев А. | Хайбуллин А. |
| 11 | Хайруллин Б. | Гайсин И. | - |

. Берләшкән Милләтләр Оешмасы Генераль Ассамблеясе карары белән 21 сентябрь Халыкара тынычлык көне буларак билгеләп үтелә. Әлеге датаның календарьга кертелгәненә быел 30 ел тулды. Тынычлык планета халкының күпчелеге өчен тормыш чынбарлыгы булса да, дөньяда атышларның тынып торганы юк әле. Тынычлык кайбер илләрдә яшәүчеләр өчен татлы хыял гына булып кала. Илебез буенча бу көнне акция үткәрелде. Безнең мәктәп тә бу чарада бик актив катшаты.






15 сентябрь көнне мәктәбебездә Татарстан варислары берлегенең туган көнен билгеләп үттек. Быел аңа 27 ел тулды.5 нче сыйныф укучылары варислар оешмасына кабул ителделәр . Бәйрәм тантанасы уен-бәйге рәвешендә үтте.Укучылар алдында төрле сынаулар куелган иде һәм алар ул каршылыкны бик тегәллек белән үттеләр. Чынлыкта, варисларга хас булган барлык кагыйдәләр биеклекләр белән таныштырды.Бу чарада без,6 сыйныфлар, актив катнаштык. Киләчәктә дә «Татарстанның Варислар берлеге» оешмасының кагыйдәләренә буйсынып яшәрбез.



Закирова Гөлинә, 6 нчы сыйныф.

## Сентябрь аенда туучы укучыларыбыз:

Абдрахманов Рифат, Вәлиуллина Әнисә, Хисматова Зәринә, Никулин Тимур, Закирова Гөлинә, Ибраһимов Зөлфәт, Кәбирова Дилбәр, Хисматов Рәсим, Хайбуллина Алсу, Замалеев Алмаз, Хайруллин Булат, Вәгыйзова Ләйсән!

Сезгә гомернең иң озынын, бәхетнең иң зурысын, шатлыкларның иң олысын юллыйбыз. Якты ал таңнар, зәңгәр күкләр сезнең күңелеңне һәрчак яктыртсын, балкытып торсын. Таң җилләренең назлысы, җан тынычлыгы, чиксез бәхетләр, укуыгызда зурдан-зур уңышлар, яхшы күтәренке кәеф юлдаш булсын сезгә. Бөтен көчегезне укуга биреп ихлас ягымлы булып калыгыз.

Зур уңышлар, яхшы күтәренке кәеф юлдаш булсын сезгә. Шат, көләч йөзле, изге күңелле булып калыгыз. Алга таба да шатлыкта, куанычта, бәхеттә яшәргә язсын!



# Нурлат районы Фома урта мәктәбе укучылары Алтын каләм—2017 фестивален яулады.

**Алтын Каләм” дә физиклар нишли?**

**“Алтын Каләм” фестиваленә килүчеләр барысы да булачак журналистлар дип ишеткән идем, тик мин кире уйладым...**

Фестивальдә икенче көнендә үк, күбесе белән танышып өлгердем.«Алтын Каләм” үз-үземә ышанычны арттырды, чөнки, үзеңә алга максат куймыйча гына, эшнең килеп чыкмавын аңладым. Журналист булыр өчен, идеялар тулып торырга тиеш, әмма нигъдер “Алтын Каләм “ вакытында “илһам”дигән төшенчә миннән әйләнеп узган чаклары да булды. Каләмчеләр барысы да диярлек, ноутбукка текәлгән- язалар, ә мин нишләргә белмим, барлык көн үзгендә диярлек темаларны алып бетерәләр дә, буш калам. Идеясыз торырга ярамый! “Алтын Каләм” соңга калмаска, һәрчак яңалык артыннан барырга өнди. “Алтын Каләм”фестиваленең бөтен Рәсәйдә билгеле икәнен интернет челтәреннән укып белсәм дә, үз күзләрең белән карап кайтуга җитми инде! Фестиваль барышында “Иң оялчаннарга, йокы чүлмәкләренә урын юк “,-дип тәгәл әйтә алам. Барыр алдыннан күпме генә шикләнсәм дә, хәзер мин бик шат, мондый шәп “Алтын Каләм”дә катнашу бәхете бар кешегә дә тәтеми әле.

Таныша торгач, аларның күбесе бөтенләй дә журналистика буенча түгел, ә башка профессияне сайлаганнар икән. Физика, җәмгыять белеме фәннәреннән имтихан тапшыручылар “Каләм” дә нишләп йөриләр соң? Хобби булачак профессиягә бер дә комачау итми. Физик та журналист һөнәрен үзләштерсә әллә зыян буламы? Язучы Халисә Ширмән дә белмичә генә әйтмәгәндер:”Сез дөньяны үзгәртергә сәләтле яшьләр”. Димәк, бу чыннан да дөрес, каләм бар кешене дә берләштерә, уртак фикергә китерә алырдай бөек корал булып чыга. Ә барлык каләм тотучыларыбыз фестивальдә җыелган. Шулай итеп, монда иң көчле атмосфера идарә итә.

Менә бит “Алтын Каләм” нинди сәләтле! “Алтын Каләм” булмаса, физиклар әле тагы кайчан җыелып, газетлар чыгарыр иде?

Алия Гафурова,



фестиваль проходил в поселке Боровое Матюшино в молодежном центре «Волга» с 26 июня по 30 июня. На заочном республиканском этапе компетентным жюри было отсмотрено более 200 полноценных портфолио с журналистскими материалами из 38 муниципальных образований Республики Татарстан. В течение 5 дней 126 юных конкурсантов сражались за главный приз – Гран-при фестиваля «Алтын каләм – Золотое перо».

**Ежегодно в финальном этапе фестиваля принимает участие более 150 победителей муниципальных и зональных этапов «Алтын Каләм – Золотое перо» из всех городов и районов нашей республики, в том числе и из Нурлатского района.**

Ученик Фомкинской школы **Аяз Аглиуллин** стал победителем в номинации «За особый вклад в направление «Дизайн и верстка печатных изданий» .


**Бу сан өчен мәктәпнең “Яшь журналист” түгәрәге әгъзалары җаваплы**

**“КӨЗГЕ”**

**Директор:** Сафиуллин Хәлим Салихович

***“Фома урта гомуми белем мәктәбе”*** тарафыннан гамәлгә куелды.

(423012 Нурлат районы, Фома авылы, Мәктәп урамы, 18)

Газетага нигез салынды: сентябрь, 2017

Газета уку вакытларында айга бер тапкыр чыга.

Тиражы *чикләнмәгән.*

**Баш мөхәррир**: Фәхретдинова Равидә Нәгыйм кызы

**Урынбасары:** Әһлиуллин Аяз

**Дизайнер**: Гафурова Алия

**Корректор**: Әһлиуллина Гөлүсә Дамировна

**Редколлегия**:Аглетдинова Гулляр,
Хисматова Зәринә
Хайруллина Әдилә
Закирова Гөлинә
Гайнуллина Алия
Гайсина Вероника